**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**22.05.2020 г.** **№ 207**

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль район Советының 2015 елның 12 гыйнварындагы 169 номерлы карары белән расланган Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әтнә район Советы карар чыгарды:

1. Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, милек һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Әтнә муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында Әтнә район Советының 12.01.2015 ел, № 169 карары белән расланган Нигезләмәгә (20.02.2016 ел, № 26, 20.05.2019 ел, № 152 редакция) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктта "ел саен, хисап чорыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча" сүзләрен "ел саен, Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү өчен билгеләнгән срокларда" сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча халыкка игълан итәргә: http://atnya.tatarstan.ru.

Әтнә муниципаль
районы башлыгы-
район Советы Рәисе Г. Г. Хәкимов